СОВЕТ
СТАРОБАЙСАРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423745, село Старое Байсарово, ул. Школьная, д.44а

Тел/факс (885552)5-01-63
Saym.Akt@yandex.ru

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ БАЙСАР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423745, Иске Байсар авылы, Мәктәп ур..,44а

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«21» ноябрь 2019 ел** **№ 32**

**Иске Байсар авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 15.11.2019елгы гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә Иске Байсар авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Иске Байсар авыл җирлеге территориясендә 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, аларның катнашуына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, аларның саны җирлек халкының гомуми санынннан 30 проценттан да артмый, алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

-Җирлектәге, җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларның эшчәнлеген тәэмин итү: -юлларны төзекләндерү һәм карау;
җирлек халкын су, газ, электр, җылылык, ягулык белән тәэмин итү һәм суны чыгару өчен: - су үткәргечләрен төзекләндерү, җирлектәге чишмәләрне рәсмиләштереп лизенция алу;
-җирлекне төзекләндерүне оештыру өчен:
- җирлек торак пунктларында хуҗасыз территорияләрне ремонтлау һәм киртәләү
- җирлектә беренчел янгын сүндерү чараларын тәэмин итү;
- җирлектә тарихи истәлекләрне саклау, файдалану һәм таныту:
- җирлек халкына ял итү урынын булдыру һәм шартлар тудыру;
- җирлектә һәм Яңа Байсар авылында стеллалар урнаштыру;

-җирлектә ритуаль хезмәт оештыру һәм зияратларны төзекләндерүне

2. Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Өлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында " Иске Байсар авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы Р. М.Кадыйров